Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

**№159** **28.10.2019 ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 декабрендәге 135 номерлы "Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 декабрендәге 135 номерлы "Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына (2019 елның 20 маендагы 151 номерлы, 2019 елның жиденче маендагы 156 номерлы, 2019 елның 29 июльдәге 158 номерлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә "5456,8" санын "5549,1" санына алмаштырырга";
б) 2 өлештә "6526,1" санын "6613,4" санына алмаштырырга";
в) 3 өлештә "1069,3" санын "1064,3"санына алмаштырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2019 елга Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары"н әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.3. 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең 2019 нчы елга фаразланган керем күләме" н әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.4. 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасына «2019 нчы елга Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.5. 6 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2019 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү"гә үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Чыбыклыавыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары** **И.Н. Гадершин**